ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраля 2024 ел № 46

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.12.2016 елның 558 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 елның 44-ФЗ номерлы Федераль законның 100 статьясын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.12.2016 елның 558 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ведомство контролен гамәлгә ашырганда ведомство контроле органнары сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшерә, шул исәптән:

а) сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәү;

б) сатып алуларны нигезләү таләпләрен һәм сатып алуларның нигезләнгән булуын үтәү;

в) сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турындагы таләпләрне үтәү;

г) контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү һәм нигезләү, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактның бәяләре, товар берәмлегенең, эшнең, хезмәт күрсәтүнең башлангыч бәясе, товар берәмлекләренең бәясенең башлангыч суммасы, эш, хезмәт күрсәтүләр берәмлегенең башлангыч суммасы дөреслеген;

д) сатып алуларның идентификация кодлары турындагы мәгълүматка туры килү һәм әлеге сатып алуларның план-графикларында булган мәгълүматны, сатып алуларны гамәлгә ашыру турындагы хәбәрнамәләрдә, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә, контрактлар төзелгән сатып алуларда катнашучылар тарафыннан контрактлар проектлары шартларында заказчылар тарафыннан төзелгән контрактлар реестрында күрсәтелгән мәгълүматның әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү күләмен арттырмау;

е) җинаять-башкару системасы учреждениеләренә һәм предприятиеләренә, инвалидлар оешмаларына алар тәкъдим иткән контракт бәясенә карата өстенлекләр, товар, эш, хезмәт бәяләре суммалары бирү;

ж) кече эшкуарлык субъектлары, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар закупкаларында катнашуга кагылышлы таләпләрне үтәү;

з) тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү таләпләрен үтәү;

и) тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) контракт шартларын бозган очракта, заказчы тарафыннан җаваплылык чаралары күрү һәм башка гамәлләр кылу;

к) куелган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яисә контракт шартларына күрсәтелгән хезмәтләрнең туры килүе;

л) куелган товарны исәпкә алу документларында чагылуның, башкарылган эшләрнең (аның нәтиҗәсенең) яисә күрсәтелгән хезмәтләрнең үз вакытында, тулылыгы һәм дөреслеге;

м) куелган товардан файдалануның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яисә сатып алуны гамәлгә ашыру максатларына күрсәтелгән хезмәтләрнең туры килүе.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**